РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
СТАРОСТУДЕНЕЦКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ СУЫКСУ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** Иске Суыксу авылы **КАРАР**

31 март 2025 ел № 1-98

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Суыксу авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Суыксу авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең генераль планын раслау турында» 2012 елның 20 декабрендәге 2-26 номерлы карарын гамәлдән чыгару хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга, «Шәһәр төзелеше эшчәнлегендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән һәм Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2025 елның 24 мартындагы 329/о номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Иске Суыксу авыл җирлегенең генераль планын раслау турында» боерыгы белән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Иске Суыксу авыл җирлеге Советы

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Суыксу авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Суыксу авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең генераль планын раслау турында» 2012 елның 20 декабрендәге 2-26 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга;
2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча басылып чыккан көннән үз көченә керә: http:pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында түбәндәге адрес буенча халыкка игълан ителергә тиеш: https://buinsk.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Иске Суыксу авыл җирлеге башлыгы М.М.Дәүләтшин